КҮРЕНЕКЛЕ КОМПОЗИТОР
Салих Сәйдәшевнең башкаладагы музеен ни өчен һаман төзекләндереп бетерә алмыйлар?
> 3

КАДЕРЛЕ КҮЧТӘНӘЧ
Ватанны сакларга киткән егетләргә кемнәр ярдәм итә?
> 3

ТЕАТР КАҺАРМАНЫ
Россиянең һәм Татарстанның халык артисты Ринат Таҗетдиновка 85 яшь тулды
> 4

БЕРЕНЧЕ АДЫМ
«Ак барс»ка «Нефтехимик»ны җиңү җиңел булмады
> 4

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 35 (29002) | Сишәмбе | 14 март | 2023 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4604609 000131

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

Яшәеш

Яңа Чишмә районының Зирекле авылында яшәүче Әлфия Сәлахованың бу арада бик авыр чагы. Көннәрнең кисәк кенә җылытуын шулай авыр кичерә ул. «Инде ничә көннән бирле бөтен гәүдәм сызлый, кан басымы уйный. Бер эшкә кул бармый. Даруларымны эчеп кенә торам. Әле төне буе йокламыйча чыктым. Анысы шул яңгырга булган икән. Һава торышына шундый бәйле кеше инде мин. Андый көннәрдә үзем җыеп киптергән үлән чәйләре эчәм. Күбрәк бәйләргә тырышам, ул бик нык тынычландыра», – ди укучыбыз.

Илдар Мөхәммәтҗанов

ЯЗ АЯКТАН ЕКМАСЫН

Арабызда язны әнә шундый халәттә каршылаучылар шактый бүген. Ник дигәндә, республикада кисәк кенә аномаль җылы көннәр башланды. Түбәләрдән тәүлек әйләнәсе тамчы тама, аяк астында – бозлавык. Шуңа өстәп әле генә ишеп-ишеп яңгыр да явып үтте. Башка еллардан аермалы буларак, быелгы яз беренче көннәреннән үк язлыгын итә башлады.

Россия Сәламәтлек саклау министрлыгы хәтта бу уңайдан кисәтү белән дә чыгарга мәҗбүр булды. «Бозлавык шартларында егылудан һәм җәрәхәтләнүдән саклану өчен урамда йөргәндә сак булырга кирәк. Өлкән яшьтәге кешеләргә өйдән чыкмаска, чыккан очракта, таймый торган олтанлы аяк киеменнән, очлы башлы таяк белән йөрергә киңәш ителә. Шулай ук атмосфера басымының кискен үзгәрүе аркасында, йөрәк-кан тамырлары авырулары булган кешеләргә аеруча игътибарлы булырга, кан басымын даими үлчәргә, табиб киңәшләрен үтәргә, билгеләнгән даруларны эчәргә кирәк», – диелә министрлык хәбәрендә.

Казан дәүләт медицина академиясенең госпиталь һәм хастаханә терапиясе кафедрасы доценты, медицина фәннәре кандидаты Регина Ахунова сүзләренә караганда, һава торышындагы кискен үзгәрешләр вакытында кешенең кан басымы уйнарга, буыннары, биле сызларга, кәефе төшәргә мөмкин. Соңгы арада табибларга әнә шундый зарлар белән килүчеләр саны арткан.

– Һава торышы үзгәргән көннәрдә хроник чирләре булган, аеруча йөрәк-кан тамыры авыруларыннан интеккән кешеләрдән сәламәтлегенә аеруча игътибарлы булу сорала. Аларга активлыкны киметергә, ерак юлга чыгудан, очрашу-күрешүләрдән тыелып торырга кирәк. Авыртуны баса торган дарулар да кул астында торсын. Андый чакта авырту ешлыгы еш кына кешенең психологик халәтенә дә бәйле була. Тынычлык саклаучылар һава торышындагы үзгәрешләрне җиңелрәк уздыра. Шуңа күрә андый көннәрдә иң беренче чиратта тынычланырга кирәк, – ди табиб.

Регина Ахунова аномаль һава торышы сакланган көннәрне җиңелрәк уздыру өчен берничә гади генә кагыйдәне истән чыгармаска куша.

– Табиблар гел искәртеп килгән киңәшләр бу көннәрдә аеруча файдалы булыр. Шул ук тәүлегенә ким дигәндә ике литр су эчкән кеше һава торышындагы хәзерге үзгәрешләрне җиңелрәк уздырачак. Бу чорда авырдан эшкәртелә торган, майлы ризыклардан баш тартыгыз. Дөрес тукланмау аркасында сару кайнау, эч күбү, эч китү башланса, хәлегез тагын да авыраячак. Начар гадәтләрдән баш тарту, каһвә, исерткеч эчемлекләр куллану, баллы ризык ашаудан тыелып тору да хәерле. Йокыгыз туйганчы йоклагыз. Матрас белән мендәр – сыйфатлы материалдан тегелгән, уңайлы, бүлмә җилләтелгән булырга тиеш, – ди табиб.

Чаллы шәһәренең Ашыгыч медицина ярдәме хастаханәсе табиб-травматологы Булат Закиров сүзләренә караганда, соңгы арада аларга да эш икеләтә арткан. Безнең белән дә операция ясаудан бушаган арада гына сөйләшеп алды ул.

– Көннәр кисәк җылыту, аяк асты начарлану аркасында безгә ярдәм сорап килүчеләр саны кисәк артты. Бозда таеп егылганда кеше, гадәттә, кулга таяна. Шуңа күрә соңгы арада кул сыну очраклары бик күп. Аяк сыну, аяк чыгулар да күп күзәтелә. Нейрохирургларга да эш артты. Ник дигәндә, соңгы арада урамда таеп егылып, башы имгәнүчеләр шактый, – ди табиб.

Булат Закиров һава торышы начарланган көннәрдә кирәксә-кирәкмәсә урамга чыкмаска, чыккан очракта да аяк астына карап йөрергә киңәш итә. Аяк киеме дә үкчәсез, уңайлы, таймый торган, резин табанлы булырга тиеш.

– Бозлы юлдан барганда, аякларны җирдән аермыйча, чаңгы шугандагы кебек хәрәкәт итәргә кирәк. Имгәнү-җәрәхәтләнүләрдән саклану өчен шуннан да яхшысы юк. Куллар кесәдә булмасын. Юкса, андый халәттә егылган очракта, баш һәм аркага зур зыян килә. Өлкән яшьтәгеләр урамга резин очлыклы кул таягы белән генә чыксын иде, – ди табиб.

Белгечләр биргән киңәшләрнең якын көннәрдә үк кирәге чыгачак әле. Ник дигәндә, синоптиклар, 15 марттан башлап ил күләмендә климатик нормадан җылы көннәр башланачак, дип фаразлый. Татарстанда, аерым алганда, Казанда һава температурасы нормадан 0,3 градуска югарырак булыр дип көтелә. Атна уртасында Татарстанда +8 градуска кадәр җылытачак. Төнлә терекөмеш баганасы −7 градуска кадәр төшәчәк. Бу җылылык атна азагында да сакланачак. Җомга – шимбә көннәрендә урыны белән явым-төшем көтелә.

Фирая ЗАХАРОВА, үләннәр белән дәвалаучы:
– Һава торышы кискен үзгәргән көннәрдә бөтнек, мелисса, гөлҗимеш, бака яфрагы, кура җиләге, карлыган яфрагы кушып әзерләнгән чәйләр бик файдалы. Алар тынычландыра да, берочтан иммунитетны да ныгыта. Үлән чәенә чыршы ылыслары кушып җибәрсәң дә файдалы. Күпләр үлән чәе кан басымын уйнатмасмы дип борчыла. 5–6 төрле үләнне бергә кушып эчсәң, кан басымына бернинди йогынтысы булмаячак. Аларны аерым-аерым эчкәндә генә сак булырга кирәк. Һава торышында аномаль үзгәрешләр булган чорда, үлән чәйләре белән беррәттән, диңгез балыгы да ашарга кирәк. Ул шулай ук хәл кертә.

Алдан әзерләнәсе

Узган атнада җылы, явым-төшемле булу, кар тиз эрү сәбәпле, Үзәк, Идел буе һәм Себер федераль округларында 13 төбәктә су басулар күзәтелгән. Россия Гадәттән тыш хәлләр министрлыгының матбугат хезмәте хәбәр иткәнчә, бүгенгә 22 шәһәр-бистәдә 41 шәхси йортны, күпфатирлы 8 йорт подвалын, 810 шәһәр яны бакчасын, 42 күперне, 10 автомобиль юлының кайбер өлешләрен су баскан.

Шимбә көнне Министрлар Кабинетында узган утырышта Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов тиешле оешмаларга су басуга әзер торырга кушты.

Россиядә беренче урман янгыннары да теркәлгән инде. Рослесхоз җитәкчесе урынбасары Алексей Венглинский әйтүенчә, ел башыннан бирле илдә шундый 14 янгын булган. Алты төбәктә барлыгы 167 гектар мәйданда агачлар янган.

Солдатка соңлап алалар

Армиягә чакыру яшен 21гә кадәр этаплап күтәрү турында закон проекты Дәүләт Думасына кертелгән. «РИА Новости» хәбәренә караганда, документ 2026 елга кадәр күчеш чорын күздә тота.

Проектта 2024 елда – 19 яшьтән 30 яшькә кадәрге егетләрне, 2025 елда – 20 яшьтән, 2026 елда 21 яшьтән хәрби хезмәткә чакыру каралган.

Исегезгә төшерәбез: узган елның 21 декабрендә Россия оборона министры Сергей Шойгу Президент Владимир Путин катнашында узган ведомство коллегиясендә армиягә чакыру яшен 18дән 21гә кадәр этаплап арттыру, ә армиягә чакыруның чик яшен 30 яшькә җиткерүне тәкъдим иткән иде. Ел башында Думадан, быел язын 30 яшькә кадәрге егетләр армиягә чакырыла башларга мөмкин, дип хәбәр ителде. Әмма соңрак Оборона комитеты башлыгы Андрей Картаполов 2023 елда Россиядә язгы чакырылышның элеккеге кагыйдәләр буенча узачагын белдерде.

Юллар тигезләнә

Татарстан юлларында чокыр-чакырларны «ямау» эшләре башланган. Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы матбугат хезмәтеннән хәбәр ителгәнчә, моның өчен юлчылар салкын асфальт-бетон катнашмасын куллана. Министрлыкның автомобиль юллары идарәсе башлыгы Олег Казеннов сүзләренә караганда, асфальт-бетонның бу төре белән кышкы чорда да эшләргә мөмкин. Аны кар-яңгыр яуганда да, суыкта да түшиләр.

Төбәк автомобиль юлларын барлыгы 8 оешма төзекләндерә. Асфальт-бетон катнашмасын түшәү, сайлап алу һәм сыйфатын контрольдә тоту ГОСТ таләпләре буенча башкарыла.

Яңалык

Тагын арта

1 апрельдән социаль пенсиянең күләме 3,3 процентка артачак. Яңалык илдә әлеге төр түләүне алучы 4 миллионга якын кешегә кагылачак, ди белгечләр. Киләсе айдан акча кемнәргә һәм ничә сумга күбрәк булып киләчәк?

Билгеле булганча, социаль пенсия, инфляция дәрәҗәсенә карап, елга бер тапкыр арттырыла. Әмма узган ел санкцияләр һәм аңа бәйле хәлләр аркасында, әлеге төр түләүне ике тапкыр: 1 апрельдә – 8,6 процентка һәм 1 июньдә 10 процентка арттырдылар. Хәзер исә ул тагын 3,3 процентка үсәчәк.

– Россия Президенты Владимир Путин кушуы буенча, узган елның 1 июнендә минималь хезмәт хакы һәм яшәү минимумы, иминият һәм социаль пенсияләр 10 процентка артты, – дип ачыклык керткән илнең хезмәт һәм социаль яклау министры урынбасары Андрей Пудов. – Быелның 1 гыйнварыннан яшәү минимумы тагын 3,3 процентка үсте. Социаль пенсия күләмен дә әнә шул күрсәткечкә җиткерәчәкләр.

Киләсе айда түләүләр үзеннән-үзе артып киләчәк. Моның өчен социаль фонд бүлекчәләренә мөрәҗәгать итәргә кирәкми, ди белгечләр. Социаль пенсияне инвалидлар, ветераннар, туендыручысыз яки ятим калган балалар, ниндидер сәбәпләр аркасында картлык буенча иминият пенсиясе билгеләнмәүчеләр ала. Узган ел азагына алынган мәгълүматларга караганда, әлеге төр түләү илдә яшәүче 3,5 миллион кешегә билгеләнгән булган. Сүз уңаеннан, картлык буенча иминият пенсиясе, ягъни хезмәт пенсиясе, быелның 1 гыйнварыннан 4,8 процентка артты инде. Ә 2022 ел дәвамында әлеге төр түләү 19,46 процентка үскән. Апрельдә картлык буенча иминият пенсиясе артмаячак, дип тә искәрткәннәр Россия Социаль фондында.

Кемгә билгеләнүенә карап, социаль пенсиянең күләме аерыла. Мәсәлән, 1 апрельдән картлык буенча социаль пенсия 228 сум 50 тиенгә артып, 7153 сум 33 тиенгә җитәчәк.

АКЧА КЕМНӘРГӘ ҺӘМ КҮПМЕГӘ АРТА?*

Кемнәргә кагыла	31 мартка кадәр, сумнарда	1 апрельдән соң, сумнарда	Күпмегә арта
Картлык буенча социаль пенсия алучылар	6924,81	7153,33	228,52
Караучысын югалткан бала	6924,81	7153,33	228,52
Ятим бала	13849,69	14306,73	457,04
III төркем инвалид	5886,14	6080,38	194,3
II төркем инвалид	6924,81	7153,33	228,6
I төркем инвалид	13849,69	14306,73	457,04
Балачактан II төркем инвалид	13849,69	14306,73	457,04
Балачактан II төркем инвалид	16619,39	17167,83	548,44
Инвалид бала	16619,39	17167,83	548,44

*Россия Социаль фонды сайтыннан

Сүзгә-сүз

Гүзәл СӘГЫЙТОВА, Казан шәһәре башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары:

Баланы татар мәктәбендә укытып та, татар теленә нәфрәт тәрбияләп була. Шуңа күрә, телибезме-теләмибезме, без заманча креатив фикерләргә тиешбез. Җитәкчедә белем дә, заманны тоемлау да булырга тиеш.

(«Интертат»ка әңгәмәсеннән)

ТАТАРСТАНДА – АЗЫК-ТӨЛЕК БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТЕЛЕШ

Азык-төлек	Тәэмин ителеш, %
Ит	133
Сөт	159
Ашлык	152
Бәрәңге	255
Шикәр	207
Үсемлек мае	632

Өч көн рәттән кимеми

Татарстанда коронавирус йоктыручылар саны өченче көн рәттән арткан. Соңгы тәүлектә республикада тагын 193 кеше чир иярткән (11 мартта – 177, 12сендә – 184 кеше). Стопкоронавирус.рф порталы мәгълүматларыннан күренгәнчә, 9 сырхауны (алдагы көнне – 25) хастаханәгә озатырга туры килгән.

Пандемия башланганнан бирле Татарстанда барлыгы 200547 кеше коронавирус белән чирләгән. 197130 кеше савыккан, шул исәптән соңгы тәүлектә – 200. Алдагы көнне 237 кешенең савыгуы турында мәгълүм булган инде.

Республикада COVID-19 инфекциясеннән үлем-китемнәр саны, элеккечә үк – 2010. Татарстанда соңгы тапкыр мондый очрак турында 20 гыйнварда хәбәр ителде.

Тулаем алганда, Россиядә соңгы тәүлектә коронавирус йоктыруның 10268 очрагы теркәлгән. 619 сырхау хастаханәләргә китерелгән. 9476сы савыккан. 34 кеше чирдән вафат булган.



Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

Дөньяда

АКШ: БАНК ТҮНТӘРЕЛЕШЕНӘ ЕРАКМЫ?

Үткән атнада Җир шарының әле бер почмагында, әле икенчесендә «давыл хәбәрчеләре» кычкырды. Планетада бизгәк көчәя, чайкалу арта – бу шомландыра. Грузин фетнәсенең гайкаларны бушату белән төгәлләнүен беләсез инде. Гыйсъянчылыкның үсүеннән куркып, рәсми грузин хакимиятләре артка чигенделәр – чит ил агентлары турындагы җәнҗаллы канун проектын парламент кире какты. Әле шуннан соң да хөкүмәтнең һәм парламентның отставкасын таләп иткән чуалышлар тынмады.

Француз протестының җиңеләсе аңлашыла иде. Французлар күп дулыйлар, әмма һәрвакыт нәтиҗәсез. Генерал Де Голльне тәхеттән төртеп төшергәннән бирле нәтиҗәле фетнә күрсәтә алганнары юк. Голльнең отставкасы да нигездә французлар тырышлыгы түгел, АКШ һәм НАТО белән конфликт җимеше иде. 1968 елда долларга каршы чыгу харап итте аның карьерасын.

Израильдә вазгыять катлаулы. Анда дәвамлы протест акцияләре бара. 11 март кичендә ил тарихындагы иң зур мәйдан җыелды. Гыйсъянчылар саны, илнең «Haaretz» газетасы бәясенә ышансак, 500 меңгә җитә иде. Халык саны 9 миллионга тулмаган ил өчен гаҗәп зур күрсәткеч бу. Алар суд реформасыннан риза түгел. Бу ризасызлыкның өстә яткан сәбәбе генә. Чынлыкта Израильдә эш катлаулы.

Атнаның төп вакыйгасы АКШта булды дип саныйм. Америкаң регуляторы илнең зурлыгы ягыннан 16 нчы урында торган банкы – «Silicon Valley Bank»ны (Силикон үзәне банкы) япты. «Татфондбанк» түнтәрелешен хәтерлисезме? Югары технологияләрне финанслаучы Америка банкы шуңа охшаган схема белән түнтәрелде. Аның төп кертем ияләре – ай-тичылар. Шулар, кредит оешмасының хәле мөшкел икәнен чамалап, ашыгыч рәвештә акчаларын таләп итә башлады. Халык массакүләм рәвештә акча таләп итсә, бер банк та чыдамый, чөнки акча облигацияләр, хөкүмәтнең әҗәт кәгазьләре һәм башка спекуляция инструментларына тыгылган. Аларны сата башлауга, бәяләре төшә һәм чалкан яту котылгысыз. Банкирлар үз бәхетсезлекләрен Федераль резерв системасының ставканы күтәрүендә күрәләр. Ставканы күтәрдеңме, финанс мәтәлчеге көтеп кенә тора. Ставканы төшерсәң, гиперинфляция белән сыналасың. Урта юл юк, алда – һәлакәт. Силикон банкы бикләнеп, санаулы вакытлар үтүгә, тагын бер финанс оешмасы – Signature Bank җан тәслим кылды. Болар – Бөек финанс кризисының беренче карлыгачлары. Дөрес, американнар тынычландыра: зур түнтәрелеш булмаячак, вазгыять контрольдә, диләр. Кертемнәр иминиятләштерелгән, халыкка акчасы кайтарылачак (250 мең долларга кадәр). Ләкин банкларның аяк сузуы биржа түнтәрелеше дә китереп чыгарды. Югалтулар зур, чылбыр реакциясе рәвешендә. Бу юллар 13 март иртәсендә языла. АКШ ФРСы бүген ашыгыч утырышка җыела. Алар эшкә килгәнче, бездә төн җитәчәк. Әйе, зур мәтәлчекне вакытлыча туктатып торырлар. Әмма вакытлыча!

Россиядә

БӘХЕТСЕЗЛЕКТӘН КОТЫЛУ ЮЛЫ ЭЗЛӘГӘНДӘ

Көнбатыштагы зур финанс түнтәрелеше Россиягә бернинди дә уңыш вәгъдә итми. Моңарчы күрелмәгән зур кризис килә һәм аннан ишекләрне бикләп котылып калу мөмкин түгел. Американнар һәм европалылар үрле-кырлы сикергәндә, чимал бәяләре төпкә ыргытылачак. Россиянең бюджеты шулар акчасына корылган. Хәлләре начарайгач, Украинага хәрби ярдәмне туктатырлар дип тә өметләнергә ярамый. Сугышка акча һәрвакыт табыла ул. Кризис, киресенчә, масштаблы сугышка этәрәчәк. Вазгыять менә шуның белән шомлы да. Планетада Икенче Бөтендөнья сугышы алдыннан булган хәлләргә охшаш вакыйгалар күзәтелә.

Мәскәүдә икътисадчы аналитиклар сәнәгать түнтәрелешеннән котылу юлларын эзлиләр. Вариантлар бик күп түгел. Искене яңартып, совет чорындагы системага кайтуга чакыручылар ишәя. Бер бездә генә түгел, Көнбатышта да бар андый хыяллар. Газета хәбәрчесе Рим стенасына язылган «Капитализмга һәм патриархатка үлем, барлык хакимлек – Советларга!» дигән лозунгның фотокүчермәсен алды яңа гына. Капитализмны мин дә сөймим, әмма советларга мәхәббәтем дә бер дә юк. «Кызыл проект» үрдәкнең, аптырагач, күлгә арты белән чумуы кебек бер нәрсә генә ул.

Эшләр катлаулы бит шулай да. Мәскәү дәүләт университетының абруйлы галимнәре Россия бюджетының нигезе булган экспорт керемнәренең кимүе СССРның таралу сценарие белән яный, чөнки хакимият институтлары һәм бар социаль система дәүләт бюджетының тышкы чыганакларга таянуы хисабына финанслана, дип белдерәләр. Ил таралмасын өчен, үсешнең эчке чыганакларын булдырырга кирәк дип саный алар. Кыскача әйткәндә, Сталин чорындагыча, яңа индустриализация башлап җибәрергә чакыралар. Аларның карашлары «Экономическое возрождение России» дигән журналда чагыла. Сәнәгатьне инновацион яктан мотивлаштырылган бизнес кулына бирергә, моның өчен конкурс оештырырга, ресурсларны җыючыларга тапшырырга – төп идеяләре менә шул. Сәнәгать предприятиеләрен олигархлар кулыннан алып инициативага ия булган эшмәкәрләр кулына бирергә телиләр. Халыкара эш бүлешү дигән механизмны ышанычсыз дип табалар, ягъни комплектлаучы детальләрне үзебездә җитештерү кирәклеген ассызыклыйлар. Әллә ни яңалык юк инде монда, шул ук импортны алыштыру идеясе. Барлык продукцияне дә үзебездә җитештерү мөмкин булмавын аңлыйлар алар да. Үзебездә яңа технологик товарлар җитештерергә әзер торучыларга арзанлы кредитлар һәм салым өстенлекләре бирергә чакыралар. Сәнәгать белән идарә итүнең тармак системасын кире кайтару, юкка чыгарылган тармак фәнни-тикшеренү институтларын һәм конструкторлык бюроларын торгызу фикерен дә алга этәрәләр. Кәгазьдә җиңел, тормышта авыр нәрсәләр болар барысы да. Бик күп еллар һәм акча сорый торган нәрсәләр. Кризис артка тибеп ята бит инде.

РӘИС КӨНДӘЛЕГЕ

КӨНЧЫГЫШКА ЙӨЗ ТОТЫП

tatarstan.ru

Хәләл азык, хәләл туризм, хәләл тормыш... Мәгълүм булганча, Татарстан башкаласы «Россия – Ислам дөньясы: KazanForum» халыкара икътисадый форумына әзерләнә башлады. Быелгысы яңа статуста – федераль дәрәҗәдә узачак. Форум узачак көннәр дә билгеле – чара 18–20 майга билгеләнгән.

Шушы көннәрдә Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов Согуд Гарәбстанына барып, Ислам хезмәттәшлеге оешмасы генераль секретаре Хөсәен Ибраһим Таха белән очрашты. Сөйләшү нәкъ тә шул икътисадый форум турында барды.

Татарстан Ислам хезмәттәшлеге оешмасы белән актив хезмәттәшлек алып бара. Аерым алганда, бу – ислам банкингы, Ислам хезмәттәшлеге оешмасының Яшьләр форумы, Ислам дөньясы фәннәр академиясе юнәлешләрендә даими эш җайга салынган.

– Ил Президенты Владимир Путин теләктәшлеге белән, икътисадый форумга федераль статус бирелде. Быел аның кысасында 200ләп чара узачак, – диде Рөстәм Миңнеханов генераль секретарьга һәм аны да мәртәбәле кунак буларак форумга чакырды.

Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов белән Хөсәен Ибраһим Таха очрашуда ислам бизнесы турында да фикер алышты.

– Россиядә ислам бизнесы белән хезмәттәшлек итү механизмнары барлыкка килә. Татарстан шуның бер үрнәге булып тора, – диде республика җитәкчесе. – Ислам икътисады юнәлешендә зур үсеш мөмкинлекләре бар. Аерым алганда, бу – хәләл ризык, хәләл туризм, хәләл медицина юнәлешләре.

Моннан тыш очрашуда спорт темасы да кузгатылды. Искәртеп үтик: гыйнвар аенда Казанда «Kazan Hockey Cup» ислам илләре арасында беренче хоккей турниры оештырылды. Ярышта 15ләп илдән 350 катнашучы көч сынашты. Турнирның нәтиҗәсе буларак, ислам илләрендә хоккейны үстерү оешмасы да булдырылды. «Бу оешманың максаты хоккей аша балалар һәм яшьләр арасында сәламәт яшәү рәвешен алга сөрү. Турнирга ислам дөньясы илләреннән кызыксыну зур булды», – дип искәртте Рөстәм Миңнеханов.

Очрашу барышында Ислам Хезмәттәшлеге Оешмасының да бу эштә катнашу мөмкинлеге турында фикер алыштылар. «Без яшьләр юнәлешенә зур әһәмият бирәбез. Сезнең эшчәнлегегез безгә бик якын, сезнең тәкъдимнәрегезне карарга һәм аларны гамәлгә ашырырга әзер», – диде Хөсәен Ибраһим Таха.

Ул Россиягә соңгы тапкыр килүен искә төшерде һәм сәфәрнең шактый уңышлы булуын да әйтте. Казанга кунакка чакыруны да теләп кабул итте.

– Узган ел азагында Россиягә килгән идем. Аллаһ насыйп итсә, форумыгызга да килермен. Без һәрвакыт сезгә теләктәшлек күрсәтәчәкбез, – диде ул.

Форумның әһәмияте нидә?

Талия МИҢНУЛЛИНА, Татарстанның Инвестицион үсеш агентлыгы җитәкчесе:

– Форумның эшлекле программасы махсус юнәлешләргә бүленәчәк. Һәркайсында 3–10 сессия узачак. Темалар икътисадый чынбарлыкка туры килә, актуаль: халыкара хезмәттәшлек, ислам финанслары, хәләл индустрия, сәнәгать өлкәсе (аерым алганда, нефть-газ химиясе, судно һәм станоклар төзелеше), логистика һәм башкалар. Логистика хәзер аеруча да әһәмиятле һәм ул барлык санап үткән тармаклардагы мөнәсәбәтләр үсешенең төп шарты булып тора. Шуңа күрә Каспий аша Төньяк – Көньяк халыкара транспорт коридоры турында сөйләшү эшлекле программаның төп темаларының берсе булачак. «Россия – Төркия», «Россия – Мисыр», «Россия – Индонезия», «Россия – Үзбәкстан», «Россия – Азәрбайҗан», «Россия – Малайзия», «Россия – Иран» конференцияләре дә эчтәлекле булыр дип көтәбез. «Россия Хәләл Экспо» эшлекле күргәзмәсе 20 мең квадрат метр мәйданны алып торачак.
Кайбер илләр инде үзләренә стенд өчен урын алып куйды.
Икътисадый нәтиҗәләр дигәндә, беренче чиратта, бу – килешүләр, яңа партнерлар, продукция экспорты, илләр арасында товар әйләнешен арттыру.

Дәүләт Советында

Эш күрсәтсәң...

Татарстан Дәүләт Советы каршындагы Яшьләр парламенты унынчы утырышын уздырды. Ике сәгатьлек утырышта эшләнгән, эшләнмәгән һәм эшләнәсе эшләр дә, йомшак һәм мактанырлык яклар да телгә алынды.

2022 ел вакыйгаларга бай булды. Яшьләр парламенты рәисе Нина Шимина сүзен шуннан башлады. Аларның күбесе ил-көндәге вазгыятькә бәйле булган. Яшь парламент әгъзалары дәүләт хакимияте органнарында стажировкалар узу, республикакүләм һәм халыкара чаралар уздыру белән беррәттән гуманитар ярдәм җыю оештырган, «Ярдәм янәшә!» проекты кысасында дарулар тараткан.

– Закон чыгару эшчәнлегенә килгәндә, узган ел яшьләр парламентының бер тәкъдиме Идел буе федераль округы дәрәҗәсендә югары бәяләнде. Безнең активистлар балигъ булмаганнарга ата-аналары ризалыгыннан башка татуировкалар ясауны тыярга тәкъдим иттеләр, – диде парламент Рәисе.

Үз канаты астындагыларны мактады да, җитешсезлекләр турында да сөйләде ул. Аның сүзен Татарстанның яшьләр эшләре министры Ринат Садыйков дәвам итте һәм Яшьләр парламентына киләчәктә кайсы өлкәләргә игътибарны арттырырга кирәклеген сөйләде.

– Миңа калса, Татарстанның Яшьләр парламенты тагын да яхшырак һәм активрак эшли ала. Аерым алганда, закон чыгару эшчәнлегендә, шулай ук патриотик тәрбия өлкәсендә эшне көчәйтергә кирәк. Монда безнең үсеш өчен мөмкинлекләребез бихисап. Моннан тыш, бүген мин авылда яшәүче яшьләрне ишетмәдем. Ә бит парламентта районнардан вәкилләр бар. Алар утырышларда авыл яшьләрен борчыган мәсьәләләр турында сөйли ала. Моны истә тотсагыз иде, – диде ул.

Утырыш вакытында һәр парламент әгъзасының ел дәвамында күпме эш эшләгәне билгеле булды. Башкарган эшләрен балларга күчерә икән алар. Араларында бер генә балл җыймаучылар да шактый. Бу җәһәттән Татарстан Дәүләт Советының Социаль сәясәт комитеты рәисе Светлана Захарова берникадәр шелтә белдерде.

– Сез бит барыгыз да – бу урыннар өчен көрәшкән кешеләр. Ни сәбәпле үзегезне эш белән күрсәтәсегез килмидер – анысын аңламыйм. Билгеле, минем белән даими рәвештә эшләүче актив егет-кызлар да бар. Минем сүзләргә колак салып, законнар чыгару эшчәнлегендә үзегезне күрсәтә башлавыгыз да сөендерә, – диде ул.

«МИРНЫЙ»ДА ТИЗРӘК ШУА

Вяльбе, Большунов, Непряева... Узган елларда Татарстан башкаласында танылган чаңгычылар кунак булды. Казанда «Мирный» чаңгы-биатлон комплексы ачылды. Башкалада салынган чаңгы юлының тәүге җиңүчеләре дә билгеле.

Республикада яшәүчеләргә чаңгы ярышлары чит-ят түгел. Комплексны рәсми рәвештә ачу тантанасында катнашкан Татарстан Премьер-министрының беренче урынбасары Рөстәм Нигъмәтуллин сүзләренә караганда, бездә әлеге спорт төре белән 37 меңнән артык кеше шөгыльләнә.

– Чаңгы-биатлон комплексы профессиональ спортчылар гына түгел, ә сәламәт яшәү рәвешен үз итүчеләр, спортның бу төрен яратучылар да биредә чаңгы шуа алсын өчен тиешле барлык таләпләргә туры китереп төзелде. Әлеге комплекс ярдәмендә без төп максатыбыз – халыкның сәламәтлеге, спорт һәм физик культура белән даими шөгыльләнүгә таба тагын бер адым ясаячакбыз, – диде ул.

Яңа чаңгы трассасында эз дә салынды. Тантаналы чара уңаеннан, яңа комплекста «Олимпия өметләре» ярышы узды. Анда танылган спортчылар, Олимпия чемпионнары һәм республикада төрле елларда спорт мәктәпләрен тәмамлаучылар катнашты. Бәйрәмдә катнашучылар чаңгы юлында исемнәре дөнья күләмендә танылган өч тапкыр Олимпия чемпионы Александр Большунов, Олимпия чемпионнары Наталья Непряева, Алексей Червоткин һәм башкаларны да күрде.

– Кыска гына вакыт аралыгында шундый зур комплекс төзи алуыгызга бик сөендем, – диде Россиянең Чаңгы ярышлары федерациясе президенты Елена Вяльбе. – Моннан өч ел чамасы элек кенә бирегә килгәч, монда матур табигатьтән башка берни дә юк иде, бүген исә яңа комплекс ачтык. Татарстанда чаңгы ярышларын бик тиз үстерәләр. Күрерсез әле, биредә иртәдән алып кичкә кадәр балалар шөгыльләнәчәк. Татарстандагы спорт комплексында ярышлар үткәрәчәкбез. Тиздән сезнең үз йолдызчыкларыгыз да кабыначак, дип ышанам.

СССРның сигез тапкыр чемпионы Николай Зимятов әйтүенчә, мондый чаңгы-биатлон комплексы ачылу ул – ил күләмендә дә бик сирәк күренеш.

– Гадәттә спорт сарайлары, бассейннар төзиләр. Ә биредә исә чаңгы-биатлон комплексы сафка басты. Моның сере дә билгеле. Республикада спортның әлеге төренә зур игътибар бирелә, – диде ул.

Тәүге ярышларда яшь чаңгычылар профессиональ спортчылар белән төркемнәргә бүленеп көч сынашты.

tatarstan.ru

Хатын-кызлар арасында Христина Мацокина командасы, ә ир-атлар арасында Олимпия уеннарының ике тапкыр бронза призеры Александр Терентьев командасы беренче булды. Чаңгычылар карлы мәйданны ничек кенә кыздырды әле! Александр Терентьев, мәсәлән, көндәшеннән 0,09 секундка гына өлгеррәк булып чыкты.

Белем һәм тәрбия

ДӘРЕС УЛ – «ТИКТОК» ТҮГЕЛ

Укучыларга дәрестә укытучыны фото, видеога төшерүне тыймакчылар. Дәүләт Думасына әнә шундый закон проекты тәкъдим ителгән. Шул рәвешле укытучыларны укучылар җәбереннән якларга җыеналар. Тик әти-әниләр арасында моның белән килешмәүчеләр дә бар. Янәсе, бәхәсле очракларда укытучыларны җәзага тарту өчен дәлилләр калмаячак.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Видеога төшерүне туктатырга, укытырга комачауламаска! Укытучылар депутатларга шундый гозер белән мөрәҗәгать иткән. Балаларның дәрестә кызык эзләвеннән туйганнардыр, күрәсең. Мәгариф комитеты рәисе Ольга Казакова белдергәнчә, кайчак укучылар артыгын кылана: берсе төшерергә телефонын әзерләсә, икенчесе сценарий уйлап таба, өченчесе шунда катнаша. Бу – укытучы өчен хурлык.

– Бүген бездә күп кенә нәрсәләргә әти-әниләрнең ризалыгы кирәк. Ә менә укытучыдан берәү дә сорамый. Әгәр ул рөхсәт итмәсә, дәрестә фотога һәм видеога төшермәскә тиешләр дип саныйм. Дәрес ул – «ТикТок» түгел, белем алу процессы. Әйдәгез, шул хакта онытмыйк. Сыйныфларда видеокамералар урнаштырырга тәкъдим иткәндә, әти-әниләр каршы чыга. Димәк, балаларны рөхсәтсез төшерергә ярамый, ә укытучыларны ярый? Без хәзер әлеге проблеманы юридик яктан хәл итү ягын эзлибез, – ди Ольга Казакова.

Superjob сервисы уздырган сораштыру нәтиҗәләре күрсәткәнчә, Дәүләт Думасына кертелгән әлеге тәкъдимне укытучыларның 80 проценты хуплаган. Әти-әниләрнең исә яртысыннан артыграгы педагогларны камерага төшерүгә каршы. Шул ук вакытта килешмәүчеләр дә бар: андыйлар – 24 процент. Ни өчен дигәндә, бәхәсле очрак килеп чыкканда, укытучыны җәзага тартып булмаячак. Соңгы вакытта укытучы белән укучы арасында дорфалыклар, аңлашылмаучанлыклар турында еш ишетеп торабыз бит. Әти-әниләр шуңа борчыладыр, мөгаен.

Алабуга районының Олы Шүрнәк мәктәбенең ОБЖ, физкультура укытучысы Илгиз Сәлимов әйтүенчә, үзеңне телефонга төшерерлек гамәл кылмаска кирәк.

– Мин бала-чаганың укытучыны камерага төшерүенә каршы. Бер караганда, укытучы үзе дә телефон кулланмаска тиеш. Быелгы уку елыннан, балаларга дәрескә телефон алып керергә ярамый, дигән тәкъдимнәр булды. Тик ул сүздә генә калды. Без ярамый дип кисәткәндә, укучылар, кайсы законда язылган, диләр. Әгәр алып керә икән, ниндидер җәзасы булырга тиеш. Хәзер дә алып килүне дәвам итәләр. Без аларга каршы бер нәрсә дә куллана алмыйбыз, – ди Илгиз Сәлимов. – Дәресемне видеога төшергәнне күргәнем юк. Бәлкем, яшертен генә төшерәләрдер, белмим. Интернетка куярлык вакыйгалар һәм сәбәпләр булмады. Хәзер бит яшерен камераларны теләсә кайсы җиргә беркетеп төшерергә мөмкин. Теләгән бала әллә нинди хәйләсен табачак. Укытучыны түгел, ЮХИДИ хезмәткәрләрен, табибларны да камерага төшерәләр. Моны бер дә матур күренеш дип әйтеп булмый. Элек укытучыны бөтенебез тыңлады. Башка «указка» да төште, ачкычлар да очты. Беркем дә аның белән бәхәсләшмәде, өенә кайтып, аны гаепләмәде. Укырга килгәнсең икән, камерага төшереп йөрисе түгел.

Бу уңайдан Республика мәгариф хезмәткәрләренең профсоюзлар берлеге рәисе Юрий Прохоровның да фикерен сораштык.

Аның фикеренчә, укучыларның кулыннан телефонны тартып алып проблеманы хәл итеп булмый. Балаларны тәрбияләргә, дәрестә игътибарын читкә юнәлтмәсен өчен кисәтергә, аңлатырга кирәк.

– Дәресне видео, фотога төшерүне тыю яхшы вариант. Ни өчен дигәндә, укытучыларга белем бирүгә берни дә комачауламаска тиеш. Күзәтүнең башка формалары да бар. Әйтик, элек директор, урынбасарлар дәресләргә йөри иде. Бу – укытучыга методикасын анализларга, чарларга үзе бер ярдәм. Менә бу контроль дә җитә һәм педагогларга файдалы иде ул. Шуңа кайтырга кирәк, – ди Юрий Прохоров.

Әгәр закон проектын хупласалар, фотога бары мәктәп җитәкчелеге рөхсәте белән генә төшереп булачак.

Сәрия МИФТАХОВА

ЯБЫК ИШЕКЛӘР

Хат эзеннән

1993 ел. Казанның үзәк урамнарының берсендә яңа музей ачыла. Шул рәвешле үзе яшәгән йортында күренекле композитор, татар профессиональ музыка сәнгатенә нигез салган Салих Сәйдәшевнең хәтерен мәңгеләштерергә телиләр. Ләкин менә инде ничә ел әлеге музейның ишегендә – йозак.

Мәшһүр композитор Салих Сәйдәшевнең Казандагы музее 2016 елда ук ремонтка ябылды. Ремонт эшләренең әле тәмамланмавы, дөресрәге, алып барылмавы билгеле булды. Музей җитәкчесенең төрле югарылыктагы җитәкчеләргә мөрәҗәгать итеп язуларның уңай нәтиҗәләр китермәве ачыкланды. Алты-җиде ел элек башланган ремонт эшләренең ахыры да булырга тиештер бит югыйсә. Бу очракта акча юклыгын сылтау итеп кую ышандырмый. Салих Сәйдәшевне халык кына түгел, кесә каракларына кадәр хөрмәт иткән бит. Кайсыдыр елда Кызыл мәйдандагы хәрби парад Сәйдәшевнең Совет армиясе маршы музыкасы белән алып барыла. Шул вакытта аңа үз исеме язылган сәгать бүләк итәләр. Ул сәгать караклар кулына эләгеп, Салихныкы икәне билгеле булгач, караклар аңа сәгатен, гафу үтенеп, шул ук көндә китереп бирә. Без шушы караклардан да түбән дәрәҗәдәге кешеләр түгелдер бит инде? Хөрмәтле редакция, сез бу мәсьәләгә битараф калмассыз дип өметләнәсе килә.

Рәфкать ИБРАҺИМ,
Татарстанның Аксакаллар шурасы әгъзасы

Редакциябезгә менә шундый эчтәлектәге хат килде. Мәсьәләнең нидә икәне аңлашыла инде. Без моның сәбәбен ачыкларга тырыштык.

Музей тарихыннан

XX гасыр башында (1904–1911) сынчы Фердинанд Амлонг тарафыннан Казанның Горький урамында ике катлы бина төзелә. Башта ул «Хөкүмәт һәм җәмәгать оешмаларында эшләүче хезмәткәрләр җәмгыяте» клубы биналары комплексына (хәзерге Тинчурин театры бинасы) керә. 1928–1990 елларда Камал театры артистлары өчен тулай торак буларак хезмәт итә. Чирек гасыр буе – 1930–1954 елларда шушы бинаның Салих Сәйдәшев яшәгән фатирында татар музыка сәнгатенең иң күренекле әсәрләре иҗат ителә.

«Татар-информ»

Салих Сәйдәшев музееның эчке күренеше. 2022 ел.

1988 елда, мәшһүр композиторның хәтерен мәңгеләштерү максатыннан, бу бинада Салих Сәйдәшев музеена нигез салына. 1993 елның 25 июненнән ул эшли дә башлый. Музей кунакларына Сәйдәшевнең тормыш һәм иҗат юлы белән танышу өчен барлык мөмкинлекләр дә тудырыла. Беренче катта – музыкаль салон, икенче катта күргәзмә заллары була. Музейның үзенчәлеге булып «Ак зал» санала. Монда композиторның «GeorgHoffman» пианиносы тора.

Салих Сәйдәшевнең рухы, иҗат җәүһәрләре сакланган әлеге музейның ишегенә 2016 елда йозак элэләр. Сәбәбе – ремонт эшләре. Төзекләндерү эшләренең ни өчен әлегәчә тәмамланмавы сорау тудыра, билгеле.

Ике сорауга – бер җавап

Сәбәбен ачыклау өчен, беренче эш итеп, музей директоры Эльвира Низаметдиновага мөрәҗәгать иттек. Аның сүзләреннән аңлашылганча, ремонт эшләре инде төгәлләнгән диярлек, бинаның ишекләре бикле булса да, музей хезмәткәрләре эштән туктамаган. Аңлавыбызча, төп проблема – экспозицияләр булмауда. Башка сорауларны ул Татарстанның Мәдәният министрлыгы һәм Милли музей җитәкчелегенә бирүебезне үтенде.

Шуннан соң без Татарстан Милли музееның генераль директоры Алиса Вяткина исеменә хат яздык. Җавап хатының кайбер мөһим урыннарына тукталыйк.

«Салих Сәйдәшев музее 1993 елның 25 июнендә ачыла. Музей экспозицияләре 23 ел дәвамында эшләп килде һәм халык арасында популяр булды. Әмма музей эчтәлек һәм техник яктан камилләштерүне, яңа тематик бүлекләр һәм экспонатлар белән тулыландыруны таләп итә. Тагын шуны исәпкә алырга кирәк: андагы экспозицияләр билгеле бер авторлар эше (Татарстанның Сәнгать фонды рәссамнары Александр Леухин һәм Владимир Нестеренко, профессор Булат Галиев җитәкчелегендәге «Прометей» үзәге хезмәткәрләре. – **Авт.**) булуы һәм авторлык хокукларын саклау турындагы закон белән яклануы аркасында бу эшләр берничә этапта башкарыла.

2016 елда музей төзекләндерү эшләре максатыннан ябыла. 2017–2020 елларда бинаны төзекләндерү һәм реставрацияләү, аның тарихи кыяфәтен кире кайтару максатыннан эшләр башкарыла. 2020 елның ноябрендә башкарылган эшләр актына кул куела», – диелә хатта.

Рәсми җаваптан аңлашылганча, яңа экспозициянең фәнни концепциясе инде эшләнгән, Фәнни-методик совет һәм тышкы рецензентлар тарафыннан кабул ителгән. 2023 елда музейның экспозиция заллары Татарстан Милли музееның күргәзмә һәм белем бирү проектларын оештыру өчен күргәзмә планына кертелгән. Шулай ук безгә, музей ябылганнан соң, экспозициядә булган барлык экспонатлар Татарстан Милли музее фондларына тапшырылганлыгы билгеле булды. Бинаны төзекләндерү эшләре белән бергә Салих Сәйдәшевнең мемориаль коллекциясендәге кайбер әйберләр реставрацияләнә икән.

«2022 елның сентябрендә Салих Сәйдәшев музее кунаклар кабул итә башлады. 2022 елның сентябреннән декабренә кадәр биредә төрле чаралар оештырылды. Хәзерге вакытта экспозициянең дизайн-проектын башкару һәм алга таба музеефикацияләү (экспозиция һәм мультимедиа җиһазларын сатып алу, контент программасын башкару, музей әйберләрен реставрацияләү һәм сәнгати бизәлеш) өчен финанслау мәсьәләсе көн кадагында тора», – дип төгәлләнә хат.

Татарстан Мәдәният министрлыгы җитәкчелегенең дә фикерен белешер өчен, министр Ирада Әюпова исеменә хат яздык. Безгә килгән җавап хатында алдагысыннан әллә ни аерма юк иде. Төгәлрәк әйтсәк, бу юлы Милли музей җитәкчесеннән килгән хатның татарчага тәрҗемәсен кабул итеп алдык.

Ачыгыз!

Шулай итеп, «Музей кайчан ачылыр?» соравына төгәл генә җавап бирүче булмады. Бары тик эшнең әлеге дә баягы акча мәсьәләсенә килеп төртелгәнен генә ачыкладык. Салих Сәйдәшевнең туганы Рөстәм Әхмәров (композиторның апасы Әминәнең оныгы) бу мәсьәләне болай гына калдырмаска ниятли.

– Музейда чаралар уза, дигәннәр. Ә безнең алар турында ишеткән дә юк. Музейның ишекләре бикләнгәннән бирле берни белмибез… Экспозицияләргә нинди бай музей иде ул. Музейның ишекләре, һичшиксез, ачык булырга тиеш! Бу вакытка кадәр ачылмавының сәбәбен һич аңлый һәм кабул итә алмыйм. Бу мәсьәләгә игътибар бирүегез өчен рәхмәт. Язма чыгу белән, без – Салих Сәйдәшевнең туганнары, Татарстан Милли музее җитәкчесе белән күзгә-күз карап сөйләшергә ниятлибез. Кулыбызда сезгә килгән хат булыр. Ул бит әлеге музейның ни дәрәҗәдә әһәмиятле булуын исбатлый, – ди ул.

P.S. Салих Сәйдәшев – шактый катлаулы чорда яшәп иҗат иткән, тормышның ачы якларын күп күргән шәхес. Репрессия вакытында могҗиза белән генә исән калып, бар җирдән куылып, яман шешне җиңә алмыйча, 54 яшендә вафат була ул. Әмма шушы кыска гына гомерендә дә үлемсез әсәрләр иҗат итәргә, «бөек» исемен яуларга өлгерә. Бүген аның бай мирасы – ябык ишекләр артында. «Ватаным Татарстан» газетасы бу хәлгә кагылышлы яңалыкларны күзәтеп барачак.

Лилия ГЫЙМАЗОВА

САЛИХ СӘЙДӘШЕВ МУЗЕЕ ТУРЫНДА КЫЗЫКЛЫ ФАКТЛАР

➤Кайчандыр Камал театры артистлары өчен тулай торак буларак хезмәт иткән бу бинада җырчы һәм актриса Галия Кайбицкая, режиссер Марсель Сәлимҗанов, сынчы Рада Нигъмәтуллина, актерлар Шәүкәт Биктимеров, Ринат Тәҗетдинов һәм башка күренекле шәхесләрнең яшәгәне билгеле.

➤Музейда Фатыйма-Зөһрә Солтанованың көндәлеге сакланганы билгеле. Аның буенча Әмирхан Еники «Гөләндәм туташ хатирәсе» повестен язган.

➤Салих Сәйдәшев музее Биектау районының Өбрә авылында да бар. Бу авылда композиторның бабасы Бикчәнтәй, аның дүрт улы Бикмөхәммәт, Мөхәммәди, Җамалетдин (композиторның әтисе), Сабирҗан тууы, сугышка кадәр Салих Сәйдәшевнең Өбрәгә еш кайтып кунак булуы билгеле.

БЕРДӘМ КӨЧ ТАУ КҮЧЕРӘ

Ватан хакына

Егетләргә һәрнәрсә кадерле! Туган яктан килгән икәнен аңлау да көч бирә. Махсус хәрби операциядә катнашучылар яшерми: алар сагына. Әнә шул ярсуны басу өчен якыннарының бер җылы сүзе, үзләренә атап күчтәнәч җибәрүләре җитә. Алар белә: кайгыртучылар һәм көтеп торучылар булганда җиңү белән кайтачаклар.

Инде хәбәр иткәнебезчә, махсус хәрби операция зонасына туган яктан ниләр генә китми. Кемнәрдер мичләр ясыйлар, кемдер кайнатмалар әзерли, волонтерлар бар кирәк-яракны сатып ала, токмач кисеп җибәрүчеләр дә бар. «ВТ» хәбәрчесе республиканың төрле районнарында оештырылган ярдәм чараларын барлады.

Без – көчле халык

Чаллыда урнашкан «Герат кыр почтасы» хәрби-патриотик оешмасы җитәкчесе Наил Каюмов әнә шулай ди.

– Солдатларга гуманитар ярдәмне беренче тапкыр июнь аенда ук җыеп тапшырдык. Шул көннән башлап, хәрбиләргә булышам дип, кемнәр генә килми. Җитәкчеләр, эшмәкәрләр, гади халык, копилкаларын ватып, җыйган акчаларын алып килүче сабыйлар да бар, – ди Әфган сугышында катнашкан Наил Каюмов.

Соңгы вакытта аларга егетләрнең әти-әниләре, хатыннары һәм якыннары исемле посылкалар алып килә башлаган. Наил абый әйтүенчә, бөтен күчтәнәч иясенә барып җитә.

– Башта хәрбиләрдән нәрсә кирәклеген белешәбез. Кемгә нәрсә, күпме кирәген сорап, ярдәм кулы сузабыз. Хәрбиләргә хатлар кадерле. Җылы оекбашлар өчен дә рәхмәт әйтә алар, – ди ул. – Гомумән, нинди генә ярдәм булса да, егетләр бик сөенә. Үзләренә атап җибәргән күчтәнәчләр өчен кат-кат рәхмәт әйтәләр. Безнең максат – һәр үтенечне үтәп, алып барган әйберләрне егетләрнең кулларына тапшыру. Изге күңелле кешеләргә дә рәхмәтлемен мин. Авыр чакта без тагын бер кат үзебезнең көчле халык икәнне күрсәттек.

Дога сораганнар иде...

Буа районының Зур Фролов авылындагы гуманитар ярдәм склады җитәкчесе Ольга Шевелева әйтүенчә, уллары, ирләре махсус хәрби операциягә киткән хатын-кызлар аннан якыннары өчен дога кылуны сораган. Соңрак окоп шәмнәре кирәклеге ачыклана. Шуннан соң Ольга эшкә тотына. Инде бу өлкәдә тәҗрибәсе булган кешеләр белән элемтәгә чыгып, егетләргә кирәк-яракларны җыя башлыйлар. Иң элек дарулар сатып алып җибәрәләр. Егетләр белән хәбәрләшкәч, күтәреп йөртә алырлык, төтене еракка китмичә генә яна торган мичләр кирәклеген әйтәләр. Ольганың ире 31 мич әзерләп бирә.

– Безнең ярдәм иткәнне белеп, башкалар да кушылды. Җылы оекбашлар да китерделәр. Акча да җыйдык. Шулай итеп, якташ егетләргә бөтен кирәк-яракны алып җибәрдек. Алар үзләре шалтыратып рәхмәтләрен җиткерәләр. Менә шунысы бик рәхәт, – ди Ольга. – Луганск шәһәрендә 70ләп бала әти-әнисез калган. Аларны ятимнәр йортына урнаштырганнар. Шундагы җитәкчелек белән сөйләштек тә сабыйларга күчтәнәчләр җибәрергә булдык. Алар бик кызганыч. Шул сабыйларны бик тә сөендерәсе килә.

Токмач кына димәгез!

Солдатларга токмач кисеп җибәрүче ханымнарны күргәч, аптыраучылар да күп булды. Янәсе, кая инде сугыш барган җирдә аш пешереп ашасыннар ди! Шул сүзләр белән тырышып эшләп йөргән ханымнарның күңелен төшерүчеләр дә булган. Әмма кул белән токмач кисү юктан гына уйлап табылган әйбер түгел. Татар егетләренең иң яратып ашаган ризыгы бит ул. Өй җылысын шул рәвешле җиткермәкче булган алар. Яшел Үзән районында Олы Яке авылы кызлары да, Мамадыш районының Түбән Сөн авылында яшәүче ханымнар да җыелышып токмач кисте. Биектау районының Алан-Бәксәр җирлеге башлыгы Зөһрә Гарифуллина да тирә-як авылда яшәүчеләрне бергә җыеп, егетләргә токмач әзерләп җибәргән.

– Егетләргә без әзерләгән токмачлар бик кирәк. Өлешчә мобилизациягә эләккән егетләрнең әниләре белән сөйләшеп торам. Алар 4–6 кешелек блиндажларда яшиләр. Кыр кухнясында ашаталар икән. Күбрәк үзләре пешереп ашый. Егетләрнең өйләреннән китүенә 5 ай вакыт үтте. Сагыналардыр да инде. Өй ризыгы да кирәктер. Көн дә диярлек токмач ашы ашап үскән үзебезнең татар егетләре бит анда, – ди Зөһрә ханым.

«Без – монда бердәм, егетләр – тегендә бергә. Авырлыкларны әнә шулай күтәрсәң генә җиңел ул. Егетләр якыннары белән сирәк кенә элемтәдә торсалар да, мин килгәч, үз гозерләрен җиткерәләр. «Әниемне, сөйгәнемне кочакла әле», – диләр. Үзләре мине кочалар. Янәсе, шушы җылыны кайтарып җиткерәм. Алар кушкач эшлим инде. Күңелләр тула», – ди Резедә Шуралева.

Без исән!

Махсус хәрби операциядәгеләргә күчтәнәчләр ташучы егетләр белән дуслашып беттек инде. Ярдәм илтүче хатын-кыз белән аралашкан юк иде. Казанда яшәүче Резедә Шуралева волонтерлык эше белән 15 ел шөгыльләнә икән инде. Бүген алар «Без аяз күк йөзе телибез» дигән оешма булдырган, анда 271 кеше эшли.

– Мин күп кенә егетләр белән элемтәдә торам. Алар бик сирәк шалтырата. Сүзләре кыска: без исән. Солдат әниләре, хатыннары исемле посылкалар да алып килә. Һәрберсен тапшырырга тырышабыз. Без килгәч, алар яныбызга чыга. Сөйләшеп сүзләре бетми. Ун гына минут торыгыз әле, диләр. Якында шартлау тавышлары ишетелсә, мине юаталар да әле. «Курыкма, анда өйрәнүләр уза», – дигән булалар. Зарланмыйлар, авырлыкны сиздермиләр. Көчле рухлы алар, – ди Резедә. – Егетләр нәрсә сорый, без шуны алып барабыз. Генераторлар, бензин пычкылары илтәбез. Әле менә окоп шәмнәре сорадылар. Кайчак тәмле ризыклар белән чәй дә эчертәбез үзләренә. Әмма егетләргә иң кадерле күчтәнәч ул – мәктәп укучылары җибәргән хатлар. Аларны сорап алалар. Укыганда күз яшьләрен тыя алмыйлар.

Резедә ире белән ике бала үстерә. Билгеле, аны ерак юлга чыгарып җибәрү берәүгә дә җиңел түгел. Үзе дә, догалар саклап йөртә, ди. Әмма күп еллар кешеләргә ярдәм итеп яшәгәч, бу юлы да читтә кала алмаган. Резедәнең үз энесе дә махсус хәрби операциядә катнаша.

Андагыны үз күзләрем белән күргәч, тормышка бөтенләй карашым үзгәрде, ди Резедә.

– Элек зур йорт, яхшы машина, дәрәҗәле эш булса, үзебезне бик бәхетле саный идек. Әмма иң кадерле нәрсә тынычлык икән бит. Әнә шул кирәк. Тормыш бөтенләй үзгәрде шул. Телефонга килгән бер смс, бер шалтырату да шулкадәр кадерле, – ди ул.

Сөйләшеп бетергәч кенә Резедәнең кем икәнен танып алдым. Кайчандыр газета аша баласына ярдәм сораган иде ул. Ә хәзер әнә нинди зур эш башкара. Башкаларны сөендерә!

Гөлгенә ШИҺАПОВА



Гаделлекнең үз хәбәрчесе

Бервакыт шулай «Ватаным Татарстан» газетасыннан өлкән журналист Мөнир абый Абдуллин: «Рәис Мәрданович турында җылы гына, матур гына, хәер, үзең беләсең инде, зур булмаган, рәхәтләнеп укый торган якты бер мәкалә яз әле», – дип шалтыраткач, бик сөендем дә, еллар буена күңелемдә тупланган сүзләрне ак кәгазьгә төшереп, сезгә дә тәкъдим итәргә булдым.

«Гаделлекнең үз хәбәрчесе» дип язып куйдым. Гаделлек дигәне «Правда» газетасы була да, үз хәбәрчесе дигәне Рәис Мәрданович Сабиров була. Күпләр аны яхшы хәтерлиләрдер әле. «Правда» газетасы – Коммунистлар партиясе органы, Рәис абый инде Казаннан шул газетага мәкаләләр язып тора иде. Үзем әле дә, теләсә нинди газетаны кулга алгач та, фамилияләрне, кем язганын карап чыгам. Р.Сабиров дигән үз хәбәрче ул елларда вак-төяк хәбәрләр, кыска яңалыклар гына язып калмый. Саллы-саллы язмалары да гел чыгып тора иде. Казан, Татарстан, нефтьчеләр турында күп язды ул. Үзе рус телле, үзе коммунистлар органы булган газетага татар, Татарстан турында язу, ай-һай, бер дә җиңел булмагандыр. Чирек гасырга якын шунда эшли алу өчен талант та, сәләт тә, шул ук вакытта тырышлык, та белем дә кирәк булгандыр. Әлбәттә инде, Рәис абыйның нәселдән килгән акылы да гомер буена озата баргандыр. Тамырлары милләтебезнең горурлыгына – дөньяга билгеле булган Максудиларга барып тоташа. Әниләре Бибидеррокыя ханым – затлы нәсел баласы. Тамырларга инкыйлаб җиле кагылгач та, югалып калмый. Әнисеннән башлангыч белем ала, тегәргә өйрәнә. Әйтерсең лә киләчәкне алдан күргән. Казаннан 35 чакрымдагы Ташсу авылы егете Шаһимәрдангә кияүгә чыга. Бер-бер артлы сигез бала дөньяга килә. Сигез бит! Әле еллары нинди – колхозлашу еллары. Мәрдан агага да кагыла ул. Колхоз рәислегеннән вакытында китеп кенә, 1937 ел афәтеннән котылып кала. Дүрт балалары Казанда укый башлагач, болай булмый бит инде, гаиләнең яртысы калада, яртысы салада дип, өйләрен Казанга күчереп салалар. Барыбер мәхәббәтле, бәхетле еллар аз, бик кыска булып чыга. Сугыш башлана да, Мәрдан ага сугышка алына, 1943 елда Орел өчен барган сугышларда соңгы баласын күрми дә башын сала. Әйтергә генә җиңел: сигез бала. Аларны бит кеше итәсе бар. Хәер, һәрберсенең акыллары үзләре белән булган шул инде. Һәрберсенә үз көнен үзе күрәсе. Оркыя апаның бөеклеге: ул балаларын гаҗәп дәрәҗәдә тату, дус, ярдәмчел итеп үстерә алган. Рәис абый җәелеп китеп сөйләп куймаса да, мин инде хәзер күз алдына яхшы китерәм. Ул бит Коръәнне аңлап укый, күп сүрәләрне яттан да белгән. Балаларына Тукай шигырьләрен, «Йосыф вә Зөләйха»ны ятлап сөйли торган булган. Үзе дә шигырьләр язган. Өй тулы мәгърифәтле вә мәдәниятле балалар үскән.

Татар матбугатының легендар шәхесе Шәмси ага Хамматов «Социалистик Татарстан» газетасының баш мөхәррирлегеннән тыныч кына лаеклы ялга җибәрелгәч, Рәис Сабировны куялар икән, дигән сүз чыккач, күп кенә язучылар, журналистлар рус телле, татар тарихын белмәгән, Мәскәүгә хезмәт иткән кеше килә, дип куркып та калалар. Ләкин юкка гына, уйланган уйларның, сөйләнгән сүзләрнең нәкъ киресе: Рәис ага ул яктан күпкә өстен булып чыкты. Ул татар телен гаҗәеп дәрәҗәдә камил белә иде. Мин фәкыйрегезгә дә аның белән ун елга якын бергә эшләргә туры килде. Ул гаҗәп итагатьле, әдәпле, югары әхлаклы кеше иде. Газета чыгарганда һич тә хата китмичә булмый. Мең, миллион хәреф, өтер, тагы әллә нинди билгеләр: йә берсе төшеп кала, йә берсе артык куела, әле генә була, шул арада әллә кая төшеп кала. Әгәр инде иртән планлаштыруда Рәис Мәрданович күтәрелеп карамый икән, димәк, хата киткән. Ул көнне ул төш авышканчы сөйләшми. Бөтен кеше хата эзли. Хата юк. Соңыннан беләбез: иҗекләр дөрес аерылмаган булган. Ул шулай матур итеп борчыла белә, шул борчылуын безгә дә күчерә. Эшкә кирәгеннән дә таләпчәнрәк булырга өйрәтә. Һәм ул үз хезмәткәрләренә ышана иде. Һәр кеше аның ышанычын акларга тырыша. Ул астыртын түгел, астан нәрсәдер оештыру аңа бөтенләй хас булмады. Аның өчен гаделлек һәр нәрсәдән, хәтта якын дустан да өстен иде. Бервакыт Рәис Мәрдановичның якын дусты Марсель Зариповның китабын Тукай премиясенә тәкъдим итәләр. Ул да озак еллар «Советская Россия» газетасында үз хәбәрче булып эшли. Бергә-бергә Казан – Мәскәү юлларында, Татарстандагы зур җыелышларда аз йөрмәгәннәр. Марсель абый нефть, сарык тиресе, бал кортлары турында матур яза, оста яза, белеп яза. «Әгәр кеше турында да Марсель шулай яза алса…» – ди Рәис Мәрданович. Һәм премия бирү комиссиясендә каршы чыга. Югыйсә Марсель Зариповның китабына, таләпчәнлекнең югары баскычы Ибраһим ага Нуруллин да уңай рецензия язган була. Рәис Мәрданович каршы тавыш бирсә дә, Марсель абыйга Дәүләт премиясен бирделәр. Ә Рәис Мәрданович үз фикерендә калды. Аңа карап кына аларның дуслыгына күләгә төшмәде кебек. Ул үзе дә яза, күп укый, тагы тәрҗемә белән шөгыльләнә иде. Шул эшләрне ул теләп, бирелеп, яратып эшли иде.

Бервакыт Фәүзия Бәйрәмова Төркиядән гаҗәп кызыклы «Сөембикә» романын алып кайтты. Аны татар хатын-кызы Илгиз Ваһап Нәүрүзхан язган. Китапны Рәис абыйга күрсәттем. Ул аны бер ай дигәндә турыдан-туры тәрҗемә итеп, машинкада басып бирде. Җитмәсә, бушлай, бер тиенсезгә. Без аны беренче Бөтендөнья конгрессы көннәрендә 25 мең тираж белән бастырып та чыгардык. Ул чакларда Рәис аганың уңганлыгына һәм төрек телен бик яхшы белүенә (әдәби әсәрне турыдан-туры аударырлык булгач инде) бик сокланган идек.

Ул бит – шәһәр егете, рус мәктәбен тәмамлаган. Казан авиация институтына укырга кергән. Мәскәүдәге махсус уку йортының төрек бүлегенә бик күпләр арасыннан сайлап алынган була. Армиядән кайткач, «Яшь сталинчы» газетасының иң түбән баскычыннан күтәрелә һәм ун елга якын «Социалистик Татарстан»ны җитәкли.

Тыйнак кеше ул Рәис абый. Югыйсә аның мәхәббәт тарихын матур итеп, су кушмыйча, чын дөресен генә язсаң да, нинди матур хикәя чыгар иде. Ул 13 яшеннән күрше кызы Айсылуга гашыйк була. Ун ел буена дуслашып йөриләр. Айсылу апа медицина институтын тәмамлый, Азнакайда эшләп кайта. 1950 елда өйләнешәләр.

Уллары – Рөстәм, Шамил. Берсе – әтисе, икенчесе әнисе хезмәтен дәвам иттерә. Рөстәм Сабиров – шагыйрь, Язучылар берлеге әгъзасы, берничә китап авторы.

Рәис абый – үзе дә шагыйрь. Ләкин күңелендәге хисләрен йөгәнләп кала алган шагыйрь. Шулай булмаса, әле олыгаеп килгән көндә дә Сергей Есенинны яттан сөйли алыр идеме?

Фәния ХУҖАХМӘТ
(«Ватаным Татарстан» газетасының 95 еллыгы уңаеннан нәшер ителгән китаптан алынды.)

КАЙГЫ УРТАКЛАШУ

Татарстан Республикасы мелиораторлары коллективы һәм «Татмелиорация» траст компаниясе» ачык акционерлык җәмгыяте җитәкчелеге, сугару-киптерү системаларыннан файдалану буенча Казан идарәсе элекке башлыгы

ДВУРЕЧЕНСКИЙ Иван Иванович

вафат булу сәбәпле, мәрхүмнең гаиләсе һәм якыннарының авыр кайгысын уртаклаша.

Спорт

ТӘРТИПЛЕ ҖИҢҮ

Зиннәтулла Билалетдинов 68 яшен тутырды. Уенчылары танылган остазның туган көнен көтеп тормады, шимбә көнне үк җиңү белән сөендерделәр. Дөрес, башта аның сабырлыгын сынадылар. «Ак барс»ка «Нефтехимик»тан өстен чыгу бик авыр бирелде.

«Ак барс»ның даими чемпионатта беренче урынны алып, плэй-оффта «Нефтехимик» белән очрашасы билгеле булгач, күпләр бу очрашуның ни белән тәмамланасын алдан ук фаразлап куйды. Сериянең 4:0 исәбе белән тәмамланасын әйтүчеләр дә аз булмады. «Кече туган» саналган Түбән Кама командасы «өлкән» булып исәпләнгән Казанга дүртенче мәртәбә Гагарин Кубогы отарга комачау итмәячәк, янәсе. «Ак барс» хоккейчылары да шулай уйлаган, күрәсең. Беренче уен «Нефтехимик» файдасына тәгәлләнде. Түбән Каманың яшь уенчыларына шул гына кирәк тә! Беренче җиңүдән рухланган егетләр тәҗрибәле көндәшләренә суларга да ирек бирмәде. Дөрес, кайчак артыгын да тырышып аттылар. «Ак барс»та осталык һәм тәҗрибә белән алдырырга ниятләсәләр, «Нефтехимик»та тизлек һәм үҗәтлеккә өметләнделәр. Килеп чыкмаса, этешеп һәм төртешеп уйнарга тырыштылар. Хәер, андый алымны «Ак барс»та да яхшы беләләр. Әйтик, Александр Радулов белән Дмитрий Воронков еш куллана аны. Әмма тәртип яратучы Зиннәтулла Билалетдинов мондый юлдан бармаячакларын әйтте. Дөрес булса, уенчыларны да ныклап кисәтеп куйганнар. Төп хоккейчылар тәүге матчларда ук җәза алса яки имгәнә башласа, ерак китеп булмаячак. Шуңа күрә Казан командасына осталык һәм тәҗрибә янына сабырлык та өстәргә туры килде. Югыйсә «Нефтехимик»ның яшь уенчыларына табиб ярдәме еш кирәк булачак иде. «Ак барс» белән Олег Знарок идарә итсә, бу очрашуларда ниләр булып бетәсен күз алдына китерүе кыен. Хәер, Казан командасы аның белән плэй-оффка беренче урыннан чыгар иде микән?

Казан командасына Түбән Камадан өстен чыгу өчен 6 уен кирәк булды. Моңарчы плэй-оффтагы ике очрашу да 4:0 исәбе белән тәмамланган иде. Бу юлы исә кызып китеп КХЛдагы бер рекордны да яңарттылар. Алтынчы очрашуда «Нефтехимик»тан Ансель Галимов 42 нче секундта ук исәпне ачты. Ә 62 нчедә Кирилл Панюков тигезләп тә куйды.

Хоккейчылар, тренерларга гына түгел, Татарстанның хоккей тамашачысына да җиңел булмады бу көннәрдә. Бар «Ак барс»ны үз итүчеләр, бар «Нефтехимик»ны якын күрүчеләр. Калганнар кем өчен җан атарга белми аптырады. Аларның игътибары күбрәк Түбән Кама ягында булгандыр дип уйларга кирәк. Сезонны рәттән 10 җиңелү белән башлаган «Нефтехимик» плэй-оффка ахырдан гына чыга алды, ә аннары Көнчыгыш конференциясендәге иң көчле командага бирешмәскә тырышты. Җанатарлар арасында исә Казан ягына үпкә белдерүчеләр дә булды. Янәсе, бөтен игътибар «Ак барс»ка. Бу урында башкала уенчыларының киемендә Татарстан гербы рәсеме барлыгын искә төшерү артык булмас. «Ак барс» – Казан командасы гына түгел.

«Беренче раунд һәрвакыт катлаулы һәм куркыныч була. Командалар яхшылап әзерләнә. Алга таба да җиңел булмаячак. Егетләр без теләгәнчә уйнарга тырышты. Һәрчак килеп чыкмаса да, тырыштылар. Иң мөһиме әнә шул, – диде Зиннәтулла Билалетдинов серия тәмамлангач. – Көндәш бик яхшы уйнады. Командалар барлык уеннарда да көрәште. Бу очрашулар безгә кимчелекләребезне күрергә мөмкинлек бирде. Ә алар бездә бар һәм төзәтергә кирәк. Көндәш безне киләсе раундка яхшылап әзерләде».

Алга таба «Ак барс»ны «Адмирал» көтә. Владивосток хоккейчылары «Салават Юлаев»ны отып, быелгы плэй-оффта иң гаҗәпләндергән командаларның берсе булып танылды. Иң кыены исә ерак сәфәргә чыгу булачак. Казандагы очрашулар 16 һәм 18 мартта узачак. Аннары «Ак барс»ка Ерак Көнчыгышка очарга туры киләчәк.

7 мартта «Нефтехимик»ка каршы узган очрашу Зиннәтулла Билалетдиновның плэй-оффтагы 121 нче матчы булды. Моңа кадәр иң зур күрсәткеч Олег Знарокта иде. Билалетдиновның плэй-офф очрашуларында 78 җиңүе бар. Олег Знарокны узу өчен тагын бер уңыш кирәк.
Тагын 3 очкога ия булса, Казан командасы капитаны Александр Радулов плэй-оффта 100 һәм аннан күбрәк очко җыйган уенчылар исемлегенә керәчәк. Әлегә андыйлар өч кеше: Сергей Мозякин (172), Данис Зарипов (128) һәм Вадим Шипачёв (116).

Илнар ХӨСНУЛЛИН


ak-bars.ru

ТЕАТР КАҺАРМАНЫ

ТАНЫЛГАН АРТИСТ РИНАТ ТАҖЕТДИНОВ 85 ЯШЬЛЕГЕН БӘЙРӘМ ИТТЕ

«Татар-информ»/Салават Камалетдинов

«Безнең сезне яратмый хәлебез юк – сез яраттырасыз». Россиянең һәм Татарстанның халык артисты Ринат Таҗетдиновның 85 яшьлек юбилеена багышланган иҗат кичәсендә Дәүләт Киңәшчесе Минтимер Шәймиев әнә шулай диде.

Галиәсгар Камал театрында узган чарага Ринат Таҗетдиновның якыннары, татар дөньясы өчен билгеле шәхесләр һәм туган ягы Чүпрәле районыннан кунаклар килгән иде. Кичә актерның иң билгеле рольләреннән – «Эзоп», «Өч аршын җир», «Сүнгән йолдызлар», «Кара чикмән», «Диләфрүзгә дүрт кияү» спектакльләреннән өзекләрдән башланды. Тик яңартылган вариантта. Алар легендар артистның үзенә багышланган иде. Ринат Таҗетдинов тамашачысы алдына җырлап килеп чыкты:

– Шушы өлкән кешенең юбилеена зал тутырып килгәнсез икән, юкка гына түгел бу. Рәхмәт бик зур! Безнең тормыш сәхнәдә узды инде һәм әле узачак. Өлкәнәйдек инде, бик күп рольләр уйнадык. Халкыбызга әйбәт хезмәт иттек дип уйлыйм. Бу – безнең сөенечебез, шатлыгыбыз. Халыкның күңелен күрү, аны яшәргә омтылдыру, халыкка хезмәт итү – бу минем эш иде, – диде халык артисты.

Кичәдә иң истә калган мизгел Минтимер Шәймиевнең котлавы булгандыр. Ни өчен дигәндә, юбиляр белән 20 минуттан артык сәхнәдә кочаклашып басып торып тәбрикләде ул аны.

– Без икәү. Безнең яшь арабыз – 6 ай. Ул әле минем энем генә. Шуны уйлап утырам әле: без сезнең белән бәхетле буын. Безнең бөек актерларыбыз булган, Аллага шөкер. Сәкинә ханым белән гомер буе театрны яраттык. Шушы актерлар уйнаган, яшәгән заманда сезнең белән шушындый бәхетле минутлар кичерәбез. Ринат Таҗетдинов үзе! Халкыбыз өчен, сәнгатебез өчен моннан да зур бәхет юк. Рәхмәт барыгызга да! Рәйсә ханым, сезгә, балаларга, кызларга, – дип сүзен башлады ул. – Без бүген, чыннан да, тарихи шәхес белән очраштык. Исәнлек-саулык телик әле үзенә! Бер караганда, әле яшь тә кебек. Актер кеше шулай булырга тиеш инде ул. Күпме хезмәт куйган – 100гә якын роль уйнаган бу егет. Тавышың да туйдырмады синең, чынлап әйтәм. Ринат тавышы бу, дип әллә кайдан ишетеп торабыз – күңелләр күтәрелеп китә. Менә шундый ышанып бетермәслек кешеләр белән яшибез! Рәхмәт халкыбызга хезмәт иткәнең өчен.

«Щепкинчыларның кайтып керүе халкыбызның гына түгел, татар сәнгатенең күтәрелеше өчен зур роль уйнады». Минтимер Шәймиев шул буын артистларны укыткан укытучыларга, театр җитәкчеләренә, артистларга рәхмәтен җиткерде:

– Анда безнең бер буын артистларыбыз тәрбияләнгән. Без укытучыларны да онытмаска тиеш. Сезнең эшләгән эшләрегез өчен бу чаклы танылулар – Россиянең һәм Татарстанның халык артисты булу, башка төрле дәрәҗәләр – үзе бер бәхет. Хезмәт куймыйча гына танылып булмый. Бу безгә ышаныч тудыра. Без әле сәнгатебезне югалтмадык, көчәйтеп кенә барабыз. Сезнең кайбер рольләрегез көндәлек тормышта гамәлгә ашты. «Баскетболист» спектаклен гомердә дә онытмыйм. Ул шул чаклы безгә сеңеп калды. Аны караганнан соң, үзебезнең чыннан да кече буйлы халык, безгә үсәргә кирәк икәнен аңладык. Мин кайчагында, спектакльдә булдымы бу, чын тормышта күрдемме мин моны, дип уйлап куям. Актерның көче, театрның көче әнә шунда инде ул. Шундый зур эз калдырасыз бит! Йөзләп роль башкарып, һәрбер рольдә сине яратып, сине хөрмәт иткәннәр икән – бу инде үзе бер батырлык. Сәнгатьнең роле тормышыбызда бик зур. Аны сез барлыкка китерәсез, сез үткәрәсез безнең йөрәккә. Сезнең керткән өлешегез дәрт тә, өмет тә уята. Тарихи актерларыбыз турында сокланып сөйлибез. Шуларның берсе бүген монда басып тора. Безнең сезне яратмый хәлебез юк – сез яраттырасыз, – диде Минтимер Шәймиев.

«Шул чакта үземне беренче тапкыр шагыйрь итеп сиздем». Татарстанның халык шагыйре Ркаил Зәйдулла Ринат Таҗетдиновның радиодан шигырьләр укуын искә алды:

– Мондый олы, мәртәбәле актерыбызның гомер бәйрәме ул – театр һәм тамашачылар өчен генә түгел, бөтен мәдәниятебез өчен олы бәйрәм, зур тантана. Театр белән әдәбият һәрвакыт бергә үрелеп бара. Мин инде спектакль өчен пьеса кирәклеге турында әйтеп тә тормыйм. Заманында Ринат абый радиодан шагыйрьләрнең шигырьләрен укып халыкка җиткерә иде. 18 яшьләр булдымы икән, үз шигырьләремне аның укуында радиодан ишеткәч, үземне беренче тапкыр шагыйрь итеп сиздем, – диде ул.

Ркаил Зәйдулла котлавын Ринат Таҗетдиновка багышлап язган шигыре белән тәмамлады. Шигырьне Камал театры артистлары дәвам итте һәм яраткан хезмәттәшен юбилее белән тәбрикләде.

– Хөрмәтле Ринат абыебыз, сезне ничек яратуыбызны, хөрмәт итүебезне бөтен труппа исеменнән әйтәм. Мин шәхсән үзем сезгә чиксез рәхмәтлемен. Балачактан сезнең белән ничек уйнаганымны әйтеп тормыйм. Сез Марсель Сәлимҗановның актеры идегез. Марсель абый киткәч, әлбәттә, кыен булгандыр. Сезгә генә түгел, бер буынга кыен булгандыр. Ләкин баш режиссер булгач, мине иң беренче булып, йөгереп килеп котлаучы сез идегез. Нәрсә генә булмасын, сез сәхнәгә, театрга тугры булып калдыгыз. Сезнең өчен тормышта төп нәрсә театр иде. Сез – театрның каһарманы. Сезнең театрга килүегез, безнең белән бергә булуыгыз – безнең өчен бик зур бәхет һәм зур җаваплылык. Исәнлек-саулык сезгә, Ринат Арифҗанович! – диде театрның баш режиссеры Фәрит Бикчәнтәев.

Соңыннан сәхнәгә кабат юбиляр үзе чыкты.

– Театр ул – бөтен халыкны берләштерә торган әйбер. Һәркемнең бәйрәме булган саен без бөтенебез монда җыелып киләбез. Чөнки ансыз булмый, без бер гаилә шикелле. Театр талантларны ярата, монда бары тик талантлы артистлар гына килә. Сәхнәне тутырып килүегез – минем өчен бихисап зур шатлык. Барыгызга да зур рәхмәт. Якташларым чыгышы – йөрәгемә май, туганнарымның килүе йөрәгемә зәмзәм суы булып ята. Өлкән кешенең күңеле йомшак була инде ул. Кешеләрне күргән саен күзгә яшь тула. Минтимер Шәриповичка аерым рәхмәт – премьераларымны калдырганы булмады. Мин инде – өлкән кеше, ләкин күңелем яшь. Әле сәхнәдә очрашырбыз, Алла боерса! – диде Ринат Таҗетдинов.

Ләйсән САФИНА

ТЕХНИК ИНСАФ ФАТЫЙХОВ:

«АРТЫШТАН КАРТИНА ЯСАУ – ТӨП ЭШЕМ ТҮГЕЛ»

Шөгыль

Инженер-конструктор иҗатны аңламый дип кем әйтә ала? Әнә Казан электр приборлары заводында инженер-конструктор булып эшләүче Кукмара егете Инсаф Фатыйхов артыштан картиналар ясый. Аның өчен табыш түгел, күңел кушкан эш белән шөгыльләнү кадерлерәк. Хезмәтләрен йорт, мунча бизәр өчен дә сатып алалар. Ясаган шәмдәлләре – үзе бер романтика. Техник егет лирик та булып чыкты.

Инсаф – Кукмара районының Кәркәүч авылы егете. Казан дәүләт энергетик университетын тәмамлаган. Бала чактан ук сызым сызарга, нәрсә дә булса уйлап табарга яраткан. Инженер-конструктор һөнәрен сайлавы очраклы түгел. Ә менә картиналар ясау белән шөгыльләнүе уйламаганда килеп чыккан. Ике ел элек социаль челтәрдә агачтан ясалган матур панного күзе төшкән. Кызыксына башлагач, артыштан ясалган картина икәнлеге ачыкланган. Әлеге агачны әллә кая барып эзләргә кирәкми. Авыл читендә үсә ул. Рәссамлык сәләте дә бар, анысы әтисе Мөниптән күчкән. Шулай итеп, картиналар иҗат итәргә тотынган егет. Туган авылында кечкенә генә остаханә ачкан.

– Артышны күрдең дә кистең түгел. Күе булып үскән урыннардагы агачларга зыян китермичә генә чистарта башладым, – ди 28 яшьлек егет. – Агачтан зур һәм кечкенә түгәрәкләр кисәм. Картина матур килеп чыксын, буш ара калмасын өчен, төрле зурлыктагысы кирәк. Ылысыннан ис чыгара торган саше (хуш ис чыгара торган кечкенә капчык) эшлим. Аңа берни дә сибәсе юк. Агачның үзәген алып, шәмдәлләр дә ясадым. Бу эштә сабырлык һәм кешенең зәвыгын аңлау кирәк.

Технологиясенә килгәндә, әллә ни катлаулы түгел. Әмма картинага туры китереп, түгәрәкләр сайлау шактый вакытны ала. Монда төгәллек сорала. Инсаф башта агачны яхшылап киптерә. Артыш ярылмый, шунысы яхшы. Төсен дә үзгәртми икән. Агачның формалары да кабатланмый. Шуңа күрә бер рәсем икенчесен кабатламый. Ябыштыру өчен фанер куллана. Җилемне махсус сайлый. Ни өчен дигәндә, картина сатып алучылар, беренче чиратта, нинди җилем белән ясыйсың, дип сорый икән. Шуңа күрә аның составына игътибар итә.

Беренче картинасы гади. Бөтен җире түгәрәктән торган яссылыкны хәтерләтә. Тик аны башкарып чыгу өчен, Инсафның өч көн вакыты киткән. Хәзер инде остарган, картинаны бер көндә үк эшләп бетерергә мөмкин. Беренче эшен дус егетенә бүләк иткән. Аннан фанерга хайван рәсемнәрен ябыштыра башлаган. Болар – аю, куян, болан, пошилар. Әлеге җәнлекләр сурәтләнгән хезмәтләр күпләрне кызыксындыра икән. Инсаф ничә картина ясаганын исәпләп бармый. Кешеләрне сөендерә алса, шул да җитә.

Егетнең хезмәтләрен берсеннән күреп икенчесе ала. Картиналарны күбрәк мунчага, ял итә торган урыннарга элү өчен сорыйлар икән. Андыйларга артыш исе чыгып тору мөһим. Кемдер әлеге картиналар белән фатирларын бизи. Шәмдәлләре йортка үзе бер сихрилек өсти.

Картинаның төгәл бәясе юк. Зурлыгына, түгәрәкләрнең никадәр тыгыз урнашуына карый икән. Алар арасында 1–3 мең сумлыгы да бар.

– Күпләр әле артышның файдасын белеп бетерми. Әлеге агачның экологик ягына игътибар итсеннәр иде. Хәзер бит ул мәсьәлә икенче планга калды. Мин беренче чиратта шуны аңлатырга тырышам. Табышы турында

әллә ни уйламыйм. Дөресрәге, бу шөгыль күңелгә рәхәтлек бирә, – ди Инсаф. – Остаханә авылда булса да, кирәкле әйберләрне фатирга алып килдек. Кичләрен хатыным Язгөл белән бергәләп эшлибез. Кәркәүчкә исә атна саен кайтырга тырышабыз.

Заводта эшләргә авырракмы, әллә иҗат эше күбрәкне таләп итәме? Техник белгечләргә сорау зурмы? Егеттән шул хакта да сорадык. «Конструкторларга ихтыяҗ артты. Беркайда җиңел түгел. Тик яратып башкарган эш бервакытта да кыенлык китерми. Әмма заводта авыррак дияр идем», – диде ул.

Сәрия МИФТАХОВА

Баш мөхәррир –
САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы

Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ

Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.

Теркәү таныклыгының номеры – 430.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.

Тираж – 5332 данә
Гомуми тираж – 15281 данә

Газетага сертификат бирелде Заказ 235

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
www.vatantat.ru
info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru
89179270040

Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР
222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.

Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.

Ваклап сату бәясе килешү буенча.

Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**

16+